Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге Советы

# КАРАРЫ

2019 елнын 28 нче феврале № 104

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге
Советының 2017 елның 13 сентябрендәге
“Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки
авыл җирлеге Советы депутаты статусы
турында”гы Нигезләмә хакында” 54 нче
номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, гамәлдәге законнар нормаларына тәңгәлләштерү максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советының 2017 елның 13 нче сентябрендәге 54 нче номерлы карары белән расланган “Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында”гы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 11 статьяның 1 өлешендәге 1 пунктчасын «сәяси партия» сүзеннән соң «билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоюз» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:

- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Сөйки авылы , Кызыл Армия урамы, авыл үзәге;
- Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Сөйки авылы , Колхоз урамы , библиотека бинасы; шулай ук мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы районы рәсми сайтында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районыСөйки авыл җирлеге
башлыгы, Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Сөйки авыл җирлеге Советы Рәисе В.П. Никитин